Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге Новоселок торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

16 октябрь, 2024 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлегенең Новоселок торак пунктында 2024 елның 16 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 61 (алтмыш бер).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 32 (утыз ике).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 32 (утыз ике).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

«Сез, 2025 елда Пановка авыл җирлеге Пановка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, Чернобыль АЭСдәге аварияне бетерүдә катнашучыларны, 1 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарын, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрне, 2 группа эшләмәүче инвалидларны, сугыш һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарын, Чернобыль АЭСдәге аварияне бетерүдә катнашучыларны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларн бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- торак пункт территориясен төзекләндерү» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Пановка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Пановка авыл җирлеге башлыгы О.И. Козырев